**Татарстан Республикасы Буа районы территориаль сайлау комиссиясе ( ИКМО вәкаләтләре белән)**

# К А Р А Р

19 ноябрь 2018 ел 3-6

**2018 елның 18 ноябрендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге территориясендә җирле референдум нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 70 статьясы, «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 56 статьясы нигезендә, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасы Буа районының территория сайлау комиссиясе (ИКМО) 2018 елның 19 ноябрендә 2018 елның 18 ноябрендә узган җирле референдум нәтиҗәләре турында беркетмә төзеде, аның нигезендә:

Тавыш бирү тәмамланган мизгелгә референдумда катнашучылар исемлекләренә 787 референдумда катнашучы кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучылар саны - 513, бу муниципаль берәмлек территориясендә референдумда катнашучылар исемлекләренә кертелгән референдумда катнашучыларның 65,18 процентын тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча референдумда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

референдумда катнашучыларның 464 (90,45 %) «Әйе» позициясе өчен тавыш бирде, Бу тавыш бирүдә катнашкан референдумда катнашучыларның 50 проценттан артыгын тәшкил итә; «Юк» позициясе өчен референдумда катнашучыларның 46 проценты тавыш бирде, бу 8,97 % тәшкил итә.

Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Буа районының территория сайлау комиссиясе (ИКМО) карар итте:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге территориясендә 2018 елның 18 ноябрендә узган референдумны узган, референдум нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. "2019 елда Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, җирле референдумда катнашу хокукына ия булган һәр гражданнан 700 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм эш төрләрен үтәү буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрүгә карата килешәсезме?

- Әлши авыл җирлегендә юлларны ремонтлау?" сорауы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Җирле референдум нәтиҗәләрен «Байрак» («Знамя», «Ялав») район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Әлши авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Татарстан Республикасы Буа районы
территориаль сайлау комиссиясе рәисе
(ИКМО) _____________ Х.К. Габдрахманов

Татарстан Республикасы Буа районы
территориаль сайлау комиссиясе секретаре
(ИКМО) _____________ Л.Р. Сафиуллина